**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3004**
**13.06.2019**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
җир участогын кире алу турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең территориясен планлаштыру һәм межалауның расланган проектында каралган җирле әһәмияткә ия объектларны төзү максатында, РФ Җир кодексының 11, 39.22, 49, 56.2, 56.3, 56.6, 56.8 маддәләре, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Мәскәү проспектының Һади Такташ урамына кадәрге дәвамында гомумшәһәр әһәмияткә ия Магистральная урамы. Челна елгасы аша күпер кичүе» объекты буенча планлаштыру һәм межалау проектын раслау турында» 2017 елның 26 июлендәге 4396 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Үзәк урамы, 99 йорт адресы буенча урнашкан Ананина Вера Николаевнаның милекчелек хокукындагы, мәйданы 1918 кв.м булган җир участогын (кадастр номеры 16:52:030715:12) кире алырга, рөхсәт ителгән файдалану төре – «индивидуаль торак төзелеше өчен».

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, закон тәртибендә билгеләнгәнчә, әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогына хокукы булган затка җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

4) кире алу нәтиҗәсендә туктатылган хокукларны һәм китерелгән зыянның күләмен бәяләү, шулай ук кире алынган күчемсез милеккә алмашка бирелә торган күчемсез милекне бәяләү өчен бәяләүче оешманы билгеләргә;

5) җир участогын кире алу буенча эш йомгаклары буенча дәүләт

муниципаль милкендә булган җир участогына, шәхси милектә булган җир участогына алмашу килешүе әзерләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин